**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 8 ноябрендәге 4684 номерлы карары**

**Хәрби техника күргәзмәсен уздыру чорына транспорт чаралары хәрәкәтен һәм туктап торуын чикләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 18 апрелендәге 353 номерлы «Рәсми спорт ярышлары уздырганда куркынычсызлыкны тәэмин итү кагыйдәләрен раслау турында»гы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә туктатуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә:

1. **Карар бирәм**:

1.1. 2024 елның 11 ноябрендә 00.00 сәгатьтән алып 2024 елның 21 ноябрендә 24:00 сәгатькә кадәр «Үзәк» стадионы каршындагы мәйданда транспорт чаралары хәрәкәтен һәм туктап торуларын чикләүне кертергә;

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.2.1. вакытлыча юл билгеләрен урнаштыру схемасын эшләргә, вакытлыча юл билгеләрен урнаштыру һәм гамәлдәге юл билгеләрен каплау буенча чаралар оештырырга;

1.2.2. транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (И.И.Сәлахетдинов) Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов

һәм Идел буе районнары администрациясе белән берлектә (А.И.Салихов) йөк техникасы яисә таранга каршы блоклар белән юлларны ябу эшен оештырырга;

1.4. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**2. Тәкъдим итәм:**

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Н.Д.Закиров) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участокларында юл хәрәкәте иминлеген саклауны контрольдә тотуны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) урам-юл челтәренең күрсәтелгән участокларында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөкләргә.**

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**